| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.01.2017 г.Казань № 1/2-пр.

Балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә алмыйча калган керемнәрен каплауга 2017 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә алмыйча калган керемнәрен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында” 2010 елның 10 сентябрендәге 1593-р номерлы күрсәтмәсен үтәү максатыннан
**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә алмыйча калган керемнәрен каплауга 2017 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

сөт эшкәртү предприятиесенә балалар ашамлыгын җитештерү өчен сатылган чимал сөтнең базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәясе арасындагы аерманы компенсацияләүгә субсидия бирү гаризасы формасын;

балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәя арасындагы аерманы каплауга субсидияләр түләү өчен бирелергә тиешле бюджет акчалары турында исәп-хисап белешмәсе формасын;

балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәя арасындагы аерманы каплауга күчерелгән субсидияләр буенча бюджет акчаларын куллану турында хисап формасын.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) азык-төлек базарын үстерү бүлеге башлыгы Е.А. Рещиковка Министрлыкның азык-төлек базарын үстерү бүлеге хезмәткәрләренең балалар ашамлыгын җитештерү өчен чимал сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдән балалар ашамлыгын җитештерү өчен

сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәя арасындагы аерманы каплауга күчерелгән субсидияләр түләү өчен бирелергә тиешле бюджет акчалары турында исәп-хисап белешмәләрен, сөт китерү шартнамәләрен, счет-фактураларны, товар-транспорт накладнойларын һәм балалар ашамлыгын җитештерүче таныклаган реестрны декада саен кабул итүен тәэмин итәргә.

3. Министрлыкның финанслау бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка “2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләрне үз вакытында күчерүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

09. 01. 2017елның 1/2-нп номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгы белән
расланды

**Балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә алмыйча калган керемнәрен каплауга 2017 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Евразия икътисад комиссиясе Советының “Сөт һәм сөт продукциясенең куркынычсызлыгы турында” 2013 елның 9 октябрендәге 67 номерлы Карары белән кабул ителгән Таможня берлегенең техник регламенты таләпләренә туры килә торган сөтне китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (алга таба – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр) алмыйча калган керемнәрен каплауга 2017 елда субсидияләр бирү тәртибен билгели.

2. Субсидияләр бирү “2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына дип (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләр бирү максаты өч яшькәчә балаларга балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә алмыйча калган керемнәрен каплаудан гыйбарәт.

4. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү өчен шартларга балалар ашамлыгы продуктларын җитештерү өчен ярашлы күрсәткечләргә ия югары сортлы сөтне бер тәүлеккә кимендә 15 тонна күләмендә җитештерү керә.

5. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр килешү төзү планлаштырылган айга кадәрге айның 1 нче числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булу һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә алып бару;

үзгәртеп оештырылу, бетерелү яки банкротлыкка чыгу стадиясендә булмау һәм хуҗалык эшчәнлеген алып баруда чикләнмәве;

Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләү срогы башланган салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына шул исәптән башка тиешле норматив хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты

узган бурычлар булмау, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына түләү вакыты узган башка төрле бурычлар булмау;

чит ил юридик затлары булмау, шулай ук теркәлү урыны салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күз алдында тотмаган (офшор зоналар) дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән, ул Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана, дәүләт яки территория булган чит ил юридик затларына устав (кушма) капиталда туры килгән өлеш барысы бергә 50 проценттан артмаган Россия юридик затлары булмау;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алучылар булып тормау.

6. Субсидияләрнең күләме өч яшькәчә балаларга балалар ашамлыгын җитештерү өчен китерелә торган 1 килограмм сөтнең базар һәм төгәл куелган бәясе арасындагы аерма буларак билгеләнә. 1 килограмм сөткә төгәл куелган бәя Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Министрлык һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр арасында төзелгән балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерү буенча килешүдә күрсәтелә.

Базар бәясе дип авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан сөтнең төп күләме җибәрелә торган сөт эшкәртү оешмаларыннан чыга торган югары сортлы сөтнең ахыргы бәясе алына (авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сөт җибәрү турында документаль расланган белешмәләре буенча).

Сатылган сөт күләме авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тапшырган сөтнең физик авырлыгы буенча билгеләнә.

7. Субсидияләр бирү критерийлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өч яшькәчә балаларга балалар ашамлыгын җитештерү өчен сыйфат күрсәткечләренә туры килә торган аксымы һәм мае җитәрлек күләмдә булган сөтне төгәл куелган бәя буенча китерергә;

кече яшьтәге балалар туклануы өчен сөттән ясалган балалар ашамлыгы продукциясенең техник регламентларда билгеләнгән таләпләргә, шулай ук Таможня берлеге комиссиясенең 2011 елның 9 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган “Азык-төлек продукциясенең куркынычсызлыгы турында” Таможня берлеге техник регламентының (ТР ТС021/2011) 8 статьясында билгеләнгән таләпләргә туры килүе һәм алар балалар сәламәтлеге өчен куркынычсыз булырга тиеш.

8. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр субсидия алу өчен Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыра:

Министрлык раслаган форма буенча, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза;

счет-фактура;

товар-транспорт накладное;

балалар ашамлыгын җитештерүчедән таныклатылган сөт китерү реестры;

Министрлык раслаган форма буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәсе;

юридик затның субсидия бирү турында шартнамә төзү планлаштырылган айга кадәрге айның 1 нче числосына Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләү вакыты чыккан бурычы булмауны раслый торган, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче җитәкчесе (башка вәкаләтле заты) тарафыннан имзаланган документ;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар, муниципаль актлар нигезендә юридик затның Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмавын раслый торган, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче җитәкчесе (башка вәкаләтле заты) тарафыннан имзаланган документ;

субсидия бирү турында гариза биргән көнгә субсидия алучыга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бетерелү, банкротлыкка чыгару, эшчәнлеге туктатылу процедуралары алып барылмау турында субсидия алучы җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хаты.

9. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә Министрлыкка Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләү вакыты чыккан бурычы булмауны раслый торган, субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айга кадәрге айның 1 нче числосыннан иртәрәк булмаган вакытка бирелгән салым органы белешмәсен тапшыру-тапшырмауны үзе хәл итәргә хокуклы.

10. Юридик зат әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта Министрлык күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмат алышу тәртибендә соратып ала.

11. Министрлык:

субсидия бирү турындагы гаризаларны кергән көннәрендә үк журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһере сугылган булырга тиеш;

тапшырылган документларны әлеге Тәртипнең 8 пунктына туры килү-килмәвен гариза теркәгән көннән алып 5 көн эчендә тикшерә һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидияләр, гаризалар бирелгән тәртип сакланып, бюджет акчалары лимиты чикләрендә бирелә.

Субсидияләр бирүдә түбәндәге очракларда баш тартыла:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән шартларга туры килмәсә;

әлеге Тәртипнец 8 пунктында каралган документлар комплектының тулы күләме тапшырылмаса;

тапшырылган документлар әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан күрсәтелгән мәгълүмат дөрес булмаса;

бюджет йөкләмәләре лимиты беткән булса.

Субсидияләр бирүдән баш тартылган очракта Министрлык, әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән срок беткәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчегә субсидия бирүдән баш тартылу турында хәбәр юллый.

Субсидияләр бирүдән баш тартуга ел дәвамында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелә ала.

12. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр белән субсидия бирү турындагы килешүне Министрлык тарафыннан расланган форма буенча һәм срокларда төзи. Министрлык субсидия бирү турында килешү формасын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән үрнәк форма нигезендә раслый.

13. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны, бирелергә тиешле субсидияләр турындагы исәп-хисап белешмәләренә нигезләнеп, үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган хосусый счетыннан авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына әлеге Тәртипнең 11 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән срок беткәннән соң биш көн эчендә күчерә.

14. Алынган субсидияләр субсидияләрнең аларны әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кереме буларак кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидияләр бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

16. Әлеге Тәртипнең 14 һәм 15 пунктларында күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемenә үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

17. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

18. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә, туры килү буенча, аларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына йөкләнә.

19. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

09.01.2017 елның 1/2-1 номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы
боерыгы белән расланды

Форма

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

_____________________М.Г. Әхмәтов
________________________, 20__ел

**20__ елның «____»______________ өчен**
**сөт эшкәртү предириятиесенә балалар ашамлыгын җитештерү өчен сатылган чимал сөтнең базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәясе арасындагы аерманы компенсацияләүгә субсидия бирүгә**
**гариза**

Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең исеме ____________________________________________________________

Урнашу урыны ______________________________________________

Банк
реквизитлары_______________________________________________

Балалар ашамлыгын җитештерү өчен чимал сөт китерү шартнамәсенең датасы, номеры _____________________________________________________

Балалар ашамлыгын җитештерү өчен 2017 елда ____________________________________________ га
сатылган чимал сөтнең базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәясе арасындагы аерманы компенсацияләүгә субсидия бирүне сорыйм.

**Кушымта:** Сөткә ветеринария-санитария экспертизасы турында ветеринария таныклыгы (форма № 2).

Җитәкче ______________________ ______________________

Баш бухгалтер ______________________ ______________________

мөһер «___»____________, 20__ ел
(булган очракта)

09.01.2017 елның 12-н номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы
боерыгы белән расланды

Форма

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министры

______________________М.Г. Әхмәтов
________________________, 20__ел

**20__ елның «____»______________ өчен**
**балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәя арасындагы аерманы каплауга субсидияләр түләү өчен бирелергә тиешле бюджет акчалары турында**
**ИСӘП-ХИСАП БЕЛЕШМӘСЕ**

| Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең исеме | Балалар ашамлыгын җитештерү өчен сатылган сөт, тонна | Субсидияләү ставкасы (базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәя арасындагы аерма), сум/килограмм | Бирелергә тиешле субсидия суммасы, (2 графа х 3 графа), мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйбыз:

Җитәкче ________________________ ________________________

Баш бухгалтер ________________________ ________________________

мөһер
(булган очракта)

09.01.2017 елның 12-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы
боерыгы белән расланды

Форма

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министры

______________________М.Г. Әхмәтов
________________________, 20__ел

**20__ елның «____»______________ өчен**
**балалар ашамлыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә базар бәясе белән төгәл билгеләнгән бәя арасындагы аерманы каплауга күчерелгән субсидияләр буенча бюджет акчаларын куллану турында**
**ХИСАП**

| Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүченең исеме | Исәп-хисап буенча бирелергә тиеш | Фактта күчерелде | Фактта түләнде |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

Искәрмә: Хисап аеннан соң килә торган айның 3 числосына кадәр ай саен тапшырыла.

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйбыз:

Җитәкче ______________________ ______________________

Баш бухгалтер ______________________ ______________________

мөһер «___»____________, 20__ ел
(булган очракта)